СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

12.12.2024 № 54-695

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнде, ул Район Советы тарафыннан хупланды һәм гавами тыңлауларда район халкы белән фикер алышуның барлык кирәкле процедураларын үтте.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставының 106-108 статьялары нигезендә, 2024 елның 19 ноябрендәге гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Е.А.Варакин

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2024 елның 12 декабреннән № 54-695 карарына №1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1.1. Уставның 6 статьясындагы 1 пунктының 28 пунктчасында «муниципаль район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Уставның 8 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. Муниципальара хезмәттәшлек.

1. Югары Ослан муниципаль районында муниципальара хезмәттәшлек федераль һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла»;

1.3. Уставның 35 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктча өстәргә:

«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы»;

1.4. Уставның 40 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 14 пунктча өстәргә:

«14. аның чит ил агенты статусы алуы»;

1.5. Уставның 41 статьясындагы 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 пунктчалар өстәргә:

«6) аның чит ил агенты статусы алуы;

7) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләргә системалы рәвештә ирешмәү»;

1.5. Уставның 45 статьясындагы 3 пунктының 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру».

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А.Варакин